**СОВЕТ**
**Кадряковского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Кадрәк авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

## РЕШЕНИЕ

## КАРАР

22.10.2020 Кадрәк авылы № 3-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 гыйнварендәге 49-1 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый анализ һәм мониторин нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 202 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарста Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге Советы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадрәк авы җирлеге» муниципаль берәмлегендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципал районының Кадрәк авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 гыйнварендәге 49- номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәг үзгәрешләр кертергә:

1.1. 16.3 пунктындагы 4 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«4) хезмәт кенәгәсе һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнард билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт шартнамәсе (контракт беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш»;

1.2. 20 бүлекнең 4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булга очракта), муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәтне узу чорында хезмә эшчәнлеге турында белешмәләр формалаштыру һәм күрсәтелгән белешмәләрн мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персоналаштырылга исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Росси Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшыру»;.

2. Карар 2021 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Карарны Кадрәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуния челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы А.А. Михайлов